**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5527**
**19.08.2021**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 елның 7 июнендәге 3888 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында урнаштыру гамәлгә ашырылырга мөмкин булган объект төрләре исемлеген раслау турында» 2014 елның 3 декабрендәге 1300 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 22 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибен раслау турында» 2021 елның 7 июнендәге 3888 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгына, Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыкларына, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибендә:

- 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электр самокатларын прокатка бирү пункты – электр самокатларын саклау (урнаштыру) өчен билгеләнгән капиталь булмаган, стационар булмаган объект яисә электр самокатларын урнаштыру мәйданчыгы (парковка зонасы)»;

- 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Электр самокатларын прокатка бирү пункты – капиталь булмаган, стационар булмаган объект Башкарма комитет карары белән билгеләнгән стационар булмаган сәүдә объектларының тышкы күренешенә карата таләпләргә туры килергә тиеш.

Электр самокатларын прокатка бирү пунктының – капиталь булмаган, стационар булмаган объектның архитектура-шәһәр төзелеше күренеше проекты Башкарма комитет карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә килештерелә.

Электр самокатларын урнаштыру мәйданчыгының (парковка зонасының) чикләре ак тоташ контур белән билгеләнергә тиеш.

Бер мәйданчыкта (парковка зонасында) уннан артык электр самокаты урнаштырылырга тиеш түгел.»;

- 5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

- 7 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) электр самокатларын индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган идентификация номеры яисә башка билгеләмә;»;

- 8 пунктның 1 пунктчасында «4-5 пунктларында» сүзләрен «4 пунктында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка, Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыкларына, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов